СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР

26.04.2024 с. Верхний Услон № 44-597

карарына

Югары Ослан муниципаль районының 2024 елның 1 кварталы өчен бюджеты үтәлеше турында

Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасы Рәисе Колесова Е.Е. Югары Ослан муниципаль районының 2024 елның 1 кварталы бюджеты үтәлеше турында мәгълүматларын тыңлап фикер алышканнан соң,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
Карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының 2024 елның 1 кварталы өчен бюджеты үтәлеше турында мәгълүматны игътибарга алырга (1 нче кушымта).
2. Муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетларына Финанс-бюджет Палатасы, Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән берлектә бюджетның барлык дәрәҗәләренә керемнәрне мобилизацияләү буенча чаралар күрергә һәм эшне көчәйтергә тәкъдим итәргә һәм салым һәм салым булмаган керемнәр буенча план бурычларын максималь үтәүне тәэмин итәргә. Салым бурычларын һәм салым булмаган керемнәр буенча бурычларны каплау эшен дәвам итәргә. Салым керемнәре керүнең артта калуы шартларында бюджетларның беренче чираттагы һәм социаль әһәмиятле чыгымнары буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә, җирле бюджетлар чыгымнарын оптимальләштерү, бюджет акчаларын сакчыл, экономияле тоту буенча реаль чаралар үткәрергә. Җирле бюджетлардан беренчел һәм социаль әһәмиятле чыгымнарны гына финанслауны гамәлгә ашыру, 2024 елның II яртыеллыгына беренчел булмаган чыгымнарны киметү. Бюджет акчаларының калган өлешләрен җибәрүне җитди контрольдә тотуны тәэмин итәргә, агымдагы ел ахырына кадәр җирле бюджетларның дефицитсыз үтәлешен тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В. Осянин

Югары Ослан муниципаль районы

Советының 2024 елның 26
апреленнән № 44-597 карарына
Кушымта №1

2024 елның 1 кварталында Югары Ослан муниципаль районының берләштерелгән бюджетын үтәү, мең сум.

| Күрсәткеч исеме | 2024нче елга план | Факт 1 квартал 2024 ел. | үтәлеш % |
|---|---|---|---|
| Җирле бюджет керемнәре | 1 007 908,7 | 259 799,0 | 25,8 |
| 1. Салым керемнәре | 622 704,4 | 120 506,6 | 19,4 |
| 1.1 физик затлар керемена салым | 384 900,0 | 73 166,2 | 19,0 |
| 1.2 акцизлар түләүдән кергән керемнәр | 44 646,4 | 11 353,9 | 25,4 |
| 1.3 салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 48 431,0 | 13 491,0 | 27,9 |
| 1.4 эшчәнлекнең аерым төрләре өчен кертелгән керемгә бердәм салым | 0,0 | 4,3 | - |
| 1.5 бердәм авыл хуҗалыгы салымы | 460,0 | 199,8 | 43,3 |
| 1.6 салым салуның патент системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 5 588,0 | 2 555,6 | 45,7 |
| 1.7 физик затлар милкенә салым | 9 062,0 | 363,7 | 4,0 |
| 1.8 җир салымы | 121 290,0 | 18 678,5 | 15,4 |
| 1.9 файдалы казылмалар чыгаруга салым | 4 782,0 | 73,0 | 1,5 |
| 1.10 дәүләт пошлинасы | 3 545,0 | 621,3 | 17,5 |
| 1.11 башка керемнәр | 0,0 | 0,0 | - |
| 2. Салым булмаган керемнәр | 36 604,2 | 15 206,0 | 41,5 |
| 2.1 дәүләт һәм муниципаль милектә булган мөлкәтне куллanudan кергән керемнәр | 17 582,0 | 2 377,9 | 13,5 |
| 2.2 әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 1 644,0 | 1 665,4 | 101,3 |
| 2.3 башка керемнәр | 17 378,2 | 11 162,7 | 64,2 |
| 3.Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 348 600,1 | 124 086,4 | 35,6 |
| 3.1 Башка дәрәҗәдәге бюджетлардан кире кайтарылмый торган керемнәр | 348 600,1 | 125 791,1 | 36,1 |
| 3.1.1 дотацияләр | 0,0 | 0,0 | - |
| 3.1.2 субсидияләр | 151 021,7 | 57 586,0 | 38,1 |
| 3.1.3 субвенцияләр | 179 635,7 | 52 123,3 | 29,0 |
| 3.1.4 башка бюджетара трансфертлар | 17 942,7 | 16 081,8 | 89,6 |
| 3.2 башка кире кайтарылмый торган кертемнәр | 0,0 | 5,0 | - |
| 3.3 Артык түләнгән яисә артык түләтелгән салымнар, җыемнар һәм башка түләүләрне кире кайтаруны (исәпкә алуны) гамәлгә ашыру өчен, шулай ук мондый кире кайтаруны | 0,0 | -357,6 | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| вакытында башкармаган өчен процентлар һәм артык түләтелгән суммаларга исәпләнгән процентлар суммасы | | | |
| 3.4 Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәре | 0,0 | 3,0 | - |
| 3.5 Узган елларның максатчан билгеләнеше булган субсидияләр, субвенцияләр һәм бюджетара трансфертларның калдыкларын кире кайтару | 0,0 | -1 355,0 | - |
| Җирле бюджет чыгымнары | 1 053 274,9 | 254 807,5 | 24,2 |
| 1.гомумдәүләт мәсьәләләре | 119 387,2 | 24 482,8 | 20,5 |
| 2.милли оборона | 2 896,8 | 724,2 | 25,0 |
| 3.милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге | 6 118,8 | 814,5 | 13,3 |
| 4.милли икътисад | 109 507,8 | 14 902,6 | 13,6 |
| 5.торак коммуналь хуҗалык | 45 718,3 | 6 151,5 | 13,5 |
| 6. әйләнә-тирә мохитне саклау | 6 882,0 | 0,0 | 0,0 |
| 7.мәгариф | 561 940,2 | 145 292,0 | 25,9 |
| 8.мәдәният, кинематография һәм массакүләм мәгълүмат чаралары | 140 299,2 | 43 477,0 | 31,0 |
| 9.Сәламәтлек саклау | 331,8 | 0,0 | 0,0 |
| 10.социаль сәясәт | 12 747,3 | 2 622,7 | 20,6 |
| 11.Физик культура һәм спорт | 38 153,9 | 13 982,1 | 36,7 |
| 12.бюджетара трансфертлар | 9 291,7 | 2 358,1 | 25,4 |
| Профицит (+), дефицит (-) | -45 366,2 | 4 991,6 | -11,0 |